353

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

23.04.2020

№ 353

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында спорт резервын әзерли торган физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләргә акчалата түләүләр тәртибен билгеләү турында

«Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында спорт резервын әзерли торган физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләргә акчалата түләүләр Тәртибен, әлеге карарга 1 нче кушымтада бәян ителгән нигезендә расларга.
2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә алам.

Җитәкче Р. М. Нуриев

Башкарма комитетының
“353” 23.04.2020 ел
карарына нче кушымта

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында спорт резервын әзерли торган физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләргә акчалата түләүләр Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә - Алабуга муниципаль районы бюджетыннан акчалата түләүләр бирү кагыйдәләрен һәм шартларын билгели.

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләргә ай саен эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 1 111 сум күләмендә, әмма аена 1 111 сумнан да артык булмаган, айлык стимуллаштыру өстәмәсе түләргә.

3. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларының баш бүлүчесе - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты.

4. Айлык стимуллаштыру өстәмәсе Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына тиешле финанс елына җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең алар тарафыннан айлык бирелә торган айлык стимуллаштыру өстәмәсе бирү өчен сайлап алу критерие булып - физкультура буенча инструктор, педагог-оештыручы, педагог-психолог, адаптив физик культура буенча инструктор-методист, адаптив физик культура буенча өлкән инструктор, тренер, адаптив физик культура буенча тренер-укытучы, хореограф, тренировка процессы администраторы, адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы вазыйфаларында эшләүче хезмәткәрләре - яшь белгечләре булган Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары булу тора.

6. Айлык стимуллаштыру өстәмәсе Министрлык һәм Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты арасында тиешле финанс елы килешүендә күрсәтелгән сроктан да соңга калмыйча төзелгән килешү нигезендә бирелә.

7. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МКУ Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында спорт резервын әзерли торган муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләрнең Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы боерыгы белән расланган реестрларын алып бара һәм һәр айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, министрлыкка башка бюджетара трансфертлар бирүнең реестрын һәм заявкасын тапшыра.

8. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты ай саен, хисап чорыннан соң килүче айның 15 көненнән дә соңга калмыйча, тармак министрлыкларына чыгымнар турында хисаплар тапшыра, аларны финанс белән тәэмин итү чыганагы булып айлык стимуллаштыру өстәмәсе бирү тора.

9. Агымдагы финанс елның 1 гыйнварына файдаланылмыйча калган акчалар Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

10. Максатчан файдалануны тикшереп торуны законнар нигезендә Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (килешү буенча) гамәлгә ашыра.